ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «21» мартыннан № 80

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлегенә керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 31 августындагы 356 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең 2023 елның 04 февралендәге ПР-18 номерлы киңәйтелгән утырышы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның йөкләмәләре исемлеге, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлегенә керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 31 августындагы 356 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле һәм эшчәнлегенә керем китерә торган башка төр хезмәтләр күрсәтү турында нигезләмәгә:

5 бүлектәге 5.3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 5.3.2 пунктча өстәргә:

«5.3.2. Түләүле чаралар оештырганда Учреждение Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге хезмәткәрләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына бушлай йөрүне билгели.».

2. Әлеге карар 2023 елның 14 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов